

Елдан ел Боек Ватан сугышы еллары бездән ерагая бара. Сугыш вакытында Ватаныбызны саклап корәшкә кvтәрелгән халкыбызнын vлемсез батырлыгы турындагы истәлекләр һәр кешенен кvнел тvрендә һәм бу хәтер юкка чыгарга тиеш тvгел. Ул еллардагы истәлекләрне кадерләп сакларга, буыннан буынга тапшырырга тиешбез. Боек Ватан сугышында Ләмберә районы Пензятка авыл советы буенча 442 кеше катнаша. Шуларнын 215се туган якларына әйләнеп кайта алмый. Аларнын исемнәре Боек Жинv елъязмасына алтын хәефләр белән язылды. Ә 1989нчы елда, авылдашларыбызнын батырлыгын мәнгеләштерv һәм киләчәк буыннарга vрнәк буларак, Пензятка урта мәктәбе бинасында «Хәтер» сугыш даны музее оештырылды. Шул вакытта авылыбызда 46 ветеран яшәде: стендларда 46 фотография, тагын сугыш вакытында ясалган фотолар да бар. Ветераннар музейга vзләренен ин истәлекле әйберләрен бvләк итте. Биргәндә, беркайчан да сугыш булмасын дип теләделәр. Полкаларда шәхси документлар, фронттан язган хатлары, рация, фотоаппарат, гимнастерка, фляжка, каска, матрос киеме – барысын санап бетереп булмый. Елдан ел фотолар астындагы туган еллары янына вафат еллары куелды. Кызганычка, бvгенге конгә авылыбызда ветераннар калмады.

Пензяткалылар арасында илебезнен ин зур хөрмәтенә лаек булган Советлар Союзы Герое - Асым Айзятулла улы Баляев. «Герой партасы» проектында катнаштык. Партада Асым Айзятулла улы Баляевнын фотосы, кыскача биографиясе, анын турында мәгълvмат язылган. Шулай ук партада мобиль жайланмалар очен QR-код урнаштырылган, аны сканерлап, укучы герой турында мәгълvмат тәкъдим ителгән рәсми порталга эләгәчәк.

Һәр ветеранныбыз орденнарга лаек. Аеруча батырлык кvрсәткәннәре очен Кызыл Йолдыз ордены Мухаррәм Үмәр улы Ипкаевка, Әхтәм Хоснетдин улы Сюбаевка, Шәйхи Али улы Хайровка, Хәйретдин Хәсән улы Якушкинга, Жәмал Шәрәфетдин улы Ямбаевка бирелгән. Алар турында материалларыбыз байтак. Боек Ватан сугышы ветераннарына багышланган стендлар янында Афган сугышында катнашучы егетләргә багышланганнары да эленеп тора. Бу материалларны музейда барган экскурсияләр вакытында, дәресләрдә, класстан тыш чараларда кулланып киләбез. Белгәнебезчә, тәрбия эшендә Ватан темасы vлемсез. «Ватан - кеше vзе туган һәм шунын гражданины булган ил; туган ил; кешенен туган ягы, туган жире» дип анлатма бирелә татар теленен анлатмалы сvзлегендә. Ә Ватанын соючене без патриот дибез. Патриотлык - Ватанга мәхәббәт хисе, анын тарихы, мәдәнияте, казанышлары белән кызыксыну, милли символларга, изге урыннарга хормәт белән карау, жәмгыятькә һәм халкына хезмәт

итәргә әзер булу. Патриотик тәрбия бирvдә тагын моһим чараларнын берсе - музейлардагы хәзинәне - тарихи экспонатларны, халкыбызнын рухи һәм матди культурасын, бvгенгесен һәм узганын чагылдыручы кыйммәтле материалларны куллану. Музеебыз материаллары нигезендә укучыларыбызда туган илгә мәхәббәт, патриотизм, халкыбызнын vткәндәге истәлекләрен хормәт итv, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли ан тәрбиялибез. Музейлар шулай ук туган якнын, туган авылнын, туган мәктәпнен тарихын ойрәнv, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәм итә. «Музееведение» тvгәрәгенә йорvче 20 укучыбыз кеше белән аралашырга, материалны жыярга, жыелган материалны тиешле дәрәжәдә туплап куярга да ойрәнәләр. Шулай без, укучылар белән бергә, эзләнv-тикшеренv эшләре белән шогыльләнәбез, торле  конференцияләрдә катнашабыз. Эшләребезнен темалары: «Халык һәм вакыт» (Боек Ватан сугышы ветераннары турында), «Пензятка авылынын тарихы», «Пензятка авылынын халык авыз ижаты», «Авылыбыздагы юрамышлар», «Пензятка мәктәбенен тарихы», «Пензятка авылынын йолалары һәм традицияләре», «Авылдашыбыз Асым Айзятулла улы Баляев - Советлар Союзы Герое», «Авылым чишмәләре», «Укытучылар - Боек Ватан сугышында катнашучылар», «Минем бабам - Боек Ватан сугышында катнашучы» (Ямбаев Сәид Үмәр улы турында). Шулай ук шәжәрә агачлары тезибез, сочинениеләр язабыз, сәнгатьле уку һәм башка ижади конкурсларда катнашабыз. Музеебызда чигелгән, тукылган солге – тастымаллар, ашъяулыклар, самовар, ипи корәге, кисәv агачы, кvмер савыты, яктырткыч, vтvк, чуен, чvлмәк кебек конкvреш әйберләре урын алган. Укучылар белән музейга торле борынгы экспонатлар жыябыз, чонки музеебызда милли почмак оештырдык. Ел саен экскурсоводлар әзерлибез, алар укучыларга һәм мәктәпкә килгән кунакларга кызык-лы экскурсияләр vткәрәләр. «Истәлек дәфтәренә» бер-ике сvз язып калдырырга тәкъдим итәләр. Алькаева Римма, Богданова Камилла белән Баляева Алина, Салякаев Ратмир (11 класслар); Никишанина Кристина (10 класс); Арикова Алина (8 класс); Хайрова Лилия, Азисова Мидина (7 класслар); Кадикина Камилла, Нугаев Артур, Казакова Сабрина (6 класслар) - ин актив укучылар, конкурсларда катнашучылар, экскурсоводлар.
Әлеге Махсус хәрби операциядә безнен Пензятка егетләре - Абдеев Рәмис, Муртазин Руслан, Рамаев Рамиль, Рамаев Рушан, Ощепков Алексей, Андриашкин Сергей катнаша. Егетләребез тиздән исән-имин әйләнеп кайтсын, илебездә тынычлык, иминлек урнашсын дип, авылдашларыбыз теләкләр тели. Алар турында да музеебызга материаллар туплап киләбез.

**Равза ЮМАЕВА***, музей житэкчесе*